КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 июнь г.Казань № 484

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 24 май, 349 нчы; 2015 ел, 30 март, 198 нче; 2016 ел, 24 март, 165 нче; 2017 ел, 22 апрель, 238 нче; 2018 ел, 9 апрель, 224 нче; 2018 ел, 10 сентябрь, 766 нчы; 2019 ел, 22 март, 214 нче, 2019 ел, 29 май, 455 нче, 2020 ел, 13 февраль, 106 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2022» саннарын «2023» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «2022» саннарын «2023» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

Программа исемендә «2022» саннарын «2023» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортында:

«Программасы исеме» юлында «2022» саннарын «2023» саннарына алмаштырырга;

«Программасын гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлында «2022» саннарын «2023» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 14 936,63 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 1 016,48 млн.сум;<br>2015 ел – 3 376,21 млн.сум;<br>2016 ел – 1 886,84 млн.сум;<br>2017 ел – 1 415,82 млн.сум;<br>2018 ел – 3 734,22 млн.сум;<br>2019 ел – 2 331,99 млн.сум;<br>2020 ел – 437,46 млн.сум;<br>2021 ел – 242,41 млн.сум;<br>2022 ел – 247,6 млн.сум;<br>2023 ел – 247,6 млн.сум<br>Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган финанслау күләме Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк»; |

«Еллар буенча бүленеп Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелегә күрсәткечләре» юлының беренче абзацында «2022» саннарын «2023» саннарына алмаштырырга»;

Программаның I бүлегендә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Программа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 17 ноябрендәге 1662-р номерлы боерыгы белән расланган 2020 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең озак сроклы социаль-икътисадый үсеше концепциясе, 2011 елның 22 апрелендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше программасы, 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе нигезендә эшләнде.»;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен тулысынча һәм дөрес исәпкә алуны тәэмин итү

Дәүләт милкен тулы һәм дөрес исәпкә алуны тәэмин итү –Татарстан Республикасы дәүләт активлары белән нәтиҗәле идарә итү нигезе.

2020 ел башына Татарстан Республикасының дәүләт активлары 449,46 млрд. сум тәшкил иткән, шул исәптән дәүләт учреждениеләренең оператив идарәсендә булган мөлкәт бәясе – 103,46 млрд.сум, дәүләт унитар предприятиеләренең хуҗалык карамагындагы мөлкәт хакы – 5,32 млрд. сум, акцияләрнең номиналь бәясе буенча дәүләт портфеле хакы – 156,23 млрд. сум, казна объектлары бәясе – 50,97 млрд. сум, Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренең кадастр бәясе – 133,48 млрд. сум.

Татарстан Республикасы территориясендә 2019 елның 1 гыйнварына җирләрнең гомуми мәйданы 6,8 млн. гектар тәшкил итте, шуларның 3,2 млн.гектары хосусый милектә һәм юридик затлар милкендә (47 процент).

Идарә хокукы буенча җир кишәрлекләре түбәндәгечә бүленә:

федераль хакимият органнары идарә итү хокукы – 1,5 млн. гектар,

муниципаль берәмлекләрнең идарә итү хокукы – 2,0 млн. гектар,

Татарстан Республикасы идарә итү хокукы – 0,07 млн. гектар.

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрында 924 юридик зат исәпләнә, шул исәптән 828 дәүләт учреждениесе, 12 унитар предприятие, устав капиталында дәүләт өлеше булган 84 хуҗалык җәмгыяте.

2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт секторы оешмалары составы динамикасы

(берәмлек)

| Состав организаций государственного сектора Республики Татарстан | 2018 елның 1 гыйнварына | 2019 елның 1 гыйнварына | 20120 елның 1 гыйнварына |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасының дәүләт секторы оешмалары саны, барлыгы | 949 | 942 | 924 |
| шул исәптән: | | | |
| унитар предприятиеләр | 19 | 16 | 12* |
| дәүләт учреждениеләре | 839 | 837 | 828 |
| устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше булган хуҗалык җәмгыятьләре | 91 | 89 | 84 |

*Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары базасында 14 дәүләт унитар предприятиесе исәпкә алынган, шул исәптән 2се – финанс-хуҗалык эшчәнлеге алып барылмый торган («Юдино» племптицесовхозы, «Татплодовощпром» концернының «Садовод» совхозы).»;

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше булган дәүләт предприятиеләре һәм акционер җәмгыятьләр белән нәтиҗәле идарә итүне, аларның хокуксызлыгын профилактикалауны тәэмин итү

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы милкендә 80 акционерлык җәмгыяте акцияләре бар. Дәүләт өлеше булмаган 15 предприятиедә «алтын акция»нең махсус хокукы кулланыла.

Дәүләтнең катнашуы түбәндәге күрсәткечләр белән характерлана:

тавыш бирүче акцияләр 100 процент – 24 җәмгыятьтә;

50дән 100 процентка кадәр – 17 җәмгыятьтә;

25 тән 50 процентка кадәр – 14 җәмгыятьтә;

25 проценттан кимрәк – 25 җәмгыятьтә.

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасының Дәүләт милке реестрында 12 дәүләт унитар предприятиесе исәпләнә.

«Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан арбитраж идарәчеләре соравы буенча бөлгенлек (банкротлык) процедурасында булган оешмалар һәм предприятиеләргә беркетелгән дәүләт милкенең булу (булмау) анализы үткәрелә. Үзенең икътисадый эшчәнлеге процессында банкротлык процедурасына күчүче эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектлары саны тотрыклы рәвештә югары булып кала бирә. Шулай ук федераль законнардагы физик затларның банкротлыгы өлешендә үзгәрешләр белән бәйле рәвештә банкротлык процедурасында булган физик затларның саны арту күзәтелә.

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә банкротлыкны булдырмый калу һәм банкротлык процедурасында булган предприятиеләрнең активларын бетермәү буенча эш алып бару өлешендә методик ярдәм күрсәтелә.

Җитештерү циклында катнашучы социаль әһәмиятле объектларны саклау кысаларында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән банкротлык процедурасында булган торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге оешмалар буенча уртак эш дәвам итә. 2019 елда әлеге эш «Югары Ослан районы коммуналь челтәрләре» ААҖ карата башкарылды.

Предприятиеләрне бетерү процедурасыннан бөлгенлек (банкротлык) процедурасына күчүне булдырмау максатыннан, шулай ук гамәлдәге предприятиеләргә карата ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән берлектә предприятиеләрнең ликвидация комиссияләре чыгымнарын һәм гамәлдәге предприятиеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау үткәрелә. Хисап чорында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары белән видеоконференция режимында ике киңәшмә үткәрелде.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә бөлгенлек (банкротлык) процедурасында булган һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында займ алу нәтиҗәсендә барлыкка килгән бурычлары булган оешмаларның кредиторлары таләпләрен реестрга кертү буенча эш алып барыла.»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт милкен һәм җир кишәрлекләреннән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү

Дәүләт учреждениеләре тарафыннан мөлкәтне файдалануны контрольдә тоту

Яңа шартларда автономияле һәм бюджет учреждениеләренә оператив идарә итү хокукы кысаларында милек белән эш итү вәкаләтләре зур күләмдә бирелә, шул ук вакытта мондый милек эшчәнлеге иреге милекченең учреждение йөкләмәләре буенча

субсидиар җаваплылыгын юкка чыгару белән компенсацияләнә.

Шуның белән бергә, милекче автоном һәм бюджет учреждениеләренә карата, закон нигезендә, алар белән идарә итү өлкәсендәге вәкаләтләрнең бер өлешен саклый. Бу – атап үтелгән учреждениеләр өчен дәүләт биремнәрен билгеләү, закон белән билгеләнгән алыш-бирешләр башкаруны килештерү, шулай ук әлеге учреждениеләргә беркетелгән күчемсез мөлкәтне һәм аеруча кыйммәтле күчемсез милекне карап тоту чыгымнарын исәпкә алып бурычларны үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыру.

Шуңа күрә ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренең законлылыгына, нәтиҗәлелегенә һәм максатчан кулланылышына системалы контроль кертелде.

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында 828 дәүләт учреждениесе исәпләнә.

2017-2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен типлар буенча бүлү

(берәмлек)

| Дәүләт учреждениесе тибы | 2018 елның 1 гыйнварына | 2019 елның 1 гыйнварына | 2020 елның 1 гыйнварына |
|---|---|---|---|
| Автономияле | 337 | 332 | 329 |
| Бюджет | 287 | 287 | 279 |
| Казна | 121 | 121 | 123 |
| Дәүләт хакимияте органнары | 94 | 97 | 97 |
| Барлыгы | 839 | 837 | 828 |

2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасының автоном учреждениеләре турында мәгълүмат

(берәмлек)

| Министрлык исеме | 2018 елның 1 гыйнварына | 2019 елның 1 гыйнварына | 2020 елның 1 гыйнварына |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Министерство здравоохранения Республики Татарстан | 144 | 139 | 134 |
| Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 95 | 94 | 93 |
| Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 65 | 66 | 68 |
| Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 19 | 19 | 20 |
| Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы | 10 | - | - |
| Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | - | 1 | 1 |
| Татарстан Республикасы спорт министрлыгы | - | 8 | 9 |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 0 | 1 | 0 |
| Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы [1] | 1 | 2 | - |

[1]Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын үзгәртеп кору турында» 2019 елның 25 сентябрендәге ПУ-574 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы итеп үзгәртелде.

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | - | - | 2 |
| Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2 | 1 | 1 |
| Татарстан Республикасы Тзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 1 | 1 | 1 |
| Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 0 | 0 | 0 |
| Барлыгы | 337 | 332 | 329 |

2019 елда ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы милкендәге һәм дәүләт учреждениеләренең оператив идарәсендәге дәүләт милкеннән файдалану, шулай ук муниципаль оешмалардан һәм аерым дәүләт учреждениеләреннән түләүсез файдалану буенча 93 күчмә тикшерү үткәрелде.

## 2016 – 2019 елларда дәүләт милкеннән файдалануны тикшерү буенча тикшерү динамикасы

(берәмлек)

| Дәүләт милкеннән файдалануны контроль тикшерүләр | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне тикшерүләр саны | 96 | 98 | 89 | 93 |
| Хокук саклау органнарына җибәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча материаллар саны | 37 | 32 | 33 | 23 |

## 2017 – 2019 елларда дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт милкеннән файдаланганда ачыкланган типик бозулар

| Бозу исеме | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Дәүләт милкен милекче ризалыгыннан башка бүтән оешмаларга тапшыру | 5 учреждение 348,33 кв. метр бина, 2 604,0 кв. метр мәйданлы 1 җир участогы тапшырды | 6 учреждение 505,32 кв. метр бина, 3 0000,0 кв. метр мәйданлы җир участогы тапшырды | 6 учреждение 2 071,11 кв. метр бина тапшырды, 2 учреждение 18 берәмлек күчемсез милек тапшырды, 2 учреждение 2 автомобиль тапшырды |
| Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү өчен белешмәләр тапшырмау | 18 объектка 9 учреждение | 12 объектка 8 учреждение | 10 объектка 8 учреждение |
| Аерым объектлар буенча оператив идарә хокукын теркәү булмау | 43 объектка 22 учреждение | 53 объектка 19 учреждение | 43 объектка 17 учреждение |
| Файдаланылмый яки нәтиҗәсез файдаланыла торган | гомуми мәйданы 14 697,0 кв. метр булган (шул исәптән 4 803,53 кв. метр булган 37 | 23 208,14 кв. метр мәйданлы 93 объект, 16,22 га мәйданлы 23 | гомуми мәйданы 15 720,93 кв. метр булган 58 объект, 2,93 га мәйданлы 4 җир |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| мөлкәт булу | объект бик канәгатьсезлек хәлдә), 15,55 га мәйданлы 22 җир кишәрлеге, 47 берәмлек автотехника | җир кишәрлеге, 55 автотехника берәмлеге | кишәрлеге, 20 берәмлек автотехника |

Файдаланылмый торган күчемсез милек объектларын инвентаризацияләү

Агымдагы елда дәүләт һәм муниципаль милектәге файдаланылмый торган күчемсез милек объектларын инвентаризацияләү нәтиҗәләре буенча 2018 елда ачыкланган файдаланылмый торган күчемсез милек объектларын хуҗалык әйләнешенә кертү буенча чаралар үткәрелде, алар дүрт төркем буенча бүленде.

Инвентаризацияләү нәтиҗәсендә билгеле булган файдаланылмый торган күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат

| Т/с | Төркемнәр | Милек | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы | | муниципаль | |
| | | объектлар саны, берәмлек | гомуми мәйдан, кв.метр | объектлар саны, берәмлек | гомуми мәйдан, кв.метр |
| 1. | Төзелеше тәмамланмаган объектлар | 3 | 3 486,6 | 14 | 42 471,7 |
| 2. | Тармакны үстерү өчен кирәк булган файдаланылмаган объектлар | 50 | 25 862,5 | 280 | 65 299,34 |
| 3. | Куллану өчен яраклы булган файдаланылмаган объектлар | 70 | 24 290,94 | 292 | 73 864,04 |
| 4. | Авария хәлендәге файдаланылмаган объектлар | 73 | 13 355,5 | 112 | 31 879,63 |
| Барлыгы | | 196 | 66 995,54 | 698 | 213 514,71 |

Үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы милкендә булган 3 төзелеп бетмәгән объект арасыннан 1 объект кулланылышка кертелгән, муниципаль милектәге 14 объекттан 2 объект өченче затлар хокукларыннан азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлегенә кертелгән.

Калган объектлар төзелешен тәмамлау һәм аларны алга таба хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү мәсьәләсен проект-смета документларын эшләгәннән һәм финанслау чыганагын билгеләгәннән соң яки исәптән төшерү турында карар кабул ителгәннән соң хәл итәргә мөмкин.

Муниципаль милектә булган тармакны үстерү өчен кирәк булган файдаланылмаган 280 объектның 68е хуҗалык әйләнешенә кертелгән, 69 объект кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан азат булган муниципаль милек исемлегенә кертелгән.

Югарыда күрсәтелгән объектларны нәтиҗәле файдалану максатыннан, аларны алга таба файдалану өчен, капиталь ремонт үткәрүгә киткән чыгымнарны исәпләргә

кирәк. Бүгенге көндә, проект-смета документларын әзерләүгә финанслау булмау сәбәпле, капиталь ремонт үткәрүгә кирәкле финанслау күләмнәре турында мәгълүматлар юк.

Татарстан Республикасы милкендә булган башка тармакларда файдалану өчен яраклы файдаланылмаган 70 объектның 7се, муниципаль милектә булган 292 объектның 19ы хуҗалык әйләнешенә кертелгән, 114 объект кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан азат булган муниципаль милек исемлегенә кертелгән.

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен хуҗалык әйләнешенә кертү сорауларын карап тикшерү тәкъдим ителде:

өченче затларның хокукларын ирекле булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлегенә кертү;

ачык аукционнарда сату яисә яки муниципаль-шәхси партнерлык механизмын куллану өчен хосусыйлаштыру планына кертү.

Татарстан Республикасы милкендә булган күчемсез милек объектларына карата, әлеге объектларны хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү мәсьәләсен түбәндәге юл белән хәл итү тәкъдим ителде:

күрсәтелгән объектларны Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре милкенә тапшыру;

ачык аукцион сатуларында сату яисә дәүләт-хосусый партнерлык механизмын куллану өчен объектларны хосусыйлаштыру планына кертү.

Инвестиция җәлеп итүчәнлеге булмаган очракта, алга таба файдалану мөмкинлекләрендә аларны исәптән төшерү мәсьәләсен карарга тәкъдим ителде.

2019 елда Татарстан Республикасы милкендә һәм муниципаль милектә булган башка тармакларда файдалану өчен яраклы булмаган объектлар белән үткәрелгән чаралар турында мәгълүмат

(берәмлек)

| Үткәрелгән чаралар | Милек | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы | муниципаль |
| Инвентаризация барышында объектлар билгеле булган | 70 | 292 |
| шул исәптән хуҗалык әйләнешенә кертелгән: | 10 | 144 |
| башка эксплуатацияләүче оешмаларга тапшырылган | 2 | 4 |
| ачык аукцион сатуларында сату өчен хосусыйлаштыру планына кертелгән | 0 | 9 |
| куллануга яраксыз дип табылды һәм исәптән төшерелергә тиеш | 0 | 2 |
| ремонт эшләрен башкару өчен проект-смета документларын эшләү буенча эшләр алып барыла | 0 | 0 |
| башкарылган | 0 | 15 |
| кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан азат булган муниципаль милек исемлегенә кертелгән | 0 | 114 |
| муниципаль милеккә тапшырылган | 5 | 0 |
| исәптән төшерелгән | 3 | 0 |

Татарстан Республикасы милкендә булган һәм исәптән төшерелергә тиешле 73 объекттан 40ы исәптән төшерелде, муниципаль милектәге 112 объекттан 8 объект исәптән чыгарылган. Моннан тыш, муниципаль милектәге 3 объект ачык аукцион сатуларында сату өчен хосусыйлаштыру планына кертелгән.

2019 елда Татарстан Республикасы милкендә һәм муниципаль милектә булган, файдалануга яраксыз һәм исәптән төшерелергә тиешле авария хәлендәге объектларга кертелгән файдаланылмаган объектлар белән үткәрелгән чаралар турында мәгълүмат

(берәмлек)

| Үткәрелгән чаралар | Милек | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы | муниципаль |
| Инвентаризация барышында объектлар билгеле булган | 73 | 112 |
| шул исәптән хуҗалык әйләнешенә кертелгән: | 40 | 11 |
| исәптән төшерелгән | 40 | 8 |
| башка эксплуатацияләүче оешмаларга тапшырылган | 0 | 0 |
| ачык аукцион сатуларында сату өчен хосусыйлаштыру планына кертелгән | 0 | 3 |

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан, килешенгән исемлеккә туры китереп, авария хәлендәге күчемсез милек объектларын исәптән алуның гадиләштерелгән схемасы буенча, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм муниципаль берәмлекләр белән берлектә, уртак эш дәвам итә.

Дәүләт мөлкәте белән идарә итүдә дәүләт-шәхси партнерлыкны куллану практикасы

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан дәүләт милкеннән нәтиҗәле файдалану максатыннан концессия килешмәләре механизмын куллану кысаларында дәүләт күчемсез милек объектларына инвестицияләр җәлеп итү буенча эш алып барыла.

2019 елның апрелендә үткәрелгән ачык конкурс нәтиҗәләре буенча ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы һәм «Казан шәһәренең Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Оренбург тракты, 140 йорт, 8 корпус, 1007 нче бүлмә адресы буенча урнашкан бинаны «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә 10 елга дәвалау туклануы хезмәтләре күрсәтү өчен тапшыру турында концессион килешмәгә кул куелды.

## 2011 – 2019 елларга дәүләт милкенә карата төзелгән концессион килешүләр турында мәгълүмат

| Ел | Килешүнең гамәлдә булу вакыты | Инвестицияләр күләме, мең сум | Объектның мәйданы, кв.метр | Объектның адресы | Инвестор | Күрсәтелә торган хезмәт |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 2011 | 10 ел | 40 000,0 | 697,4 | Казан ш., Гвардейская ур, 52/2 йорт | «АВА-ПЕТЕР» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Репродуктив сәламәтлекне саклау һәм торгызу, шул исәптән өстәмә репродуктив технологияләр (ЭКО) өлкәсендә хезмәт күрсәтү |
| 2013 | 15 ел | 15 000,0 | 714,4 | Казан ш., Һ.Такташ ур., 115 йорт | «Спасение» медицина берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары халкына түләүсез юридик ярдәм күрсәтү |
| 2014 | 7 ел | 100 000,0 | 4 745,7 | Чаллы ш., Мир ур., 12 йорт | «HD заманча медицина клиникасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Татарстан Республикасы халкына амбулатор гемодиализ хезмәтләре күрсәтү |
| 2014 | 7 ел | 60 000,0 | 2 731,5 | Түбән Кама ш., Менделеев ур., 46 йорт | «HD заманча медицина клиникасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Татарстан Республикасы халкына амбулатор гемодиализ хезмәтләре күрсәтү |
| 2014 | 7 ел | 50 000,0 | 598,9 | Бөгелмә ш., 14 Павших ур., 11 йорт, 1 нче бүлмә | «HD заманча медицина клиникасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Татарстан Республикасы халкына амбулатор гемодиализ хезмәтләре күрсәтү |
| 2017 | 10 ел | 318 000,0 | 193,8 | Казан ш., Себер тракты ур., 29 йорт, 10 нчы бүлмә | «Сакнур» Идел буе томотерапия үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Томотерапия (нур терапиясе) хезмәтләре күрсәтү |
| 2018 | 20 ел | 33 000,0 | 1 135,9 | Казан ш., Җиңү пр., 142 йорт, 1205 нче бүлмә | «Казан тернәкләндерү һәм абилитация үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы | Балалар церебраль параличлы инвалид балаларны социаль тернәкләндерү эшчәнлеге |
| 2019 | 10 ел | 50 000,0 | 1 027,5 | Казан ш., Идел буе районы, Оренбург тракты ур., 140 йорт, 8 нче корпус, 1007 бүлмә | «Казан шәһәренең Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» акционерлык җәмгыяте | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә дәвалау туклануы хезмәтләрен күрсәтү |

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына (алга таба – КУЭ) мөлкәти ярдәм күрсәтү кече һәм урта бизнесны үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары тарафыннан КУЭ субъектларына арендага, шул исәптән ташламалы шартларда да, дәүләт милке исемлекләрен раслауны күздә тота.

КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү дәүләт мөлкәтен хуҗалык әйләнешенә җәлеп итүгә, кече һәм урта бизнесның мөлкәти базасын ныгытуга ярдәм итәчәк, шул ук вакытта арендалы түләүләр керү, шулай ук арендаторларның мөлкәтен сатып алу хисабына бюджет керемен арттырачак.

Программа максатларының берсе – Татарстан Республикасы территориясендә кече һәм урта бизнесны үстерүне стимуллаштыру, шул исәптән казна объектларының мөлкәти потенциалын куллану исәбенә дә.

КУЭ мөлкәти ярдәм күрсәтү өлешендә әлеге Программаның бурычлары булып тора:

1. КУЭ субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегендә (алга таба – Исемлек) Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте санын арттыру.

2. Мөлкәтне арендага бирү буенча ташламалы тәртипне камилләштерү.

3. Ия булуга милек бирү (файдалану) процедураларының гадиләшүе һәм үтә күренмәлелеген арттыру.

Татарстан Республикасында КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү түбәндәге принципларда гамәлгә ашырыла:

мәгълүмати ачыклык (транспарантлык): «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларда Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертелгән мөлкәт турында, Исемлеккә кертелгән мөлкәт турында, мөлкәти ярдәм күрсәтүне җайга салучы хокукый актлар турында мәгълүмат урнаштыру;

КУЭ субъектларының милек ярдәме алуга тигез үтеп керүе: КУЭ субъектларына милеккә һәм (яки) файдалануга бирү турындагы карарларны әзерләү, кабул итү һәм үтәү барышында конкурентлылыкны яклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәү;

дәүләт (муниципаль) милкенә кергән, яңа ачыкланган, шулай ук кулланылмый торган, нәтиҗәсез файдаланыла торган яки билгеләнеше буенча кулланылмый торган мөлкәт исемлегенә кертү өстенлеге, дәүләт бурычларын хәл итү өчен дәүләт хакимияте органнарын яки дәүләт оешмаларын урнаштыру өчен кирәк булган очраклардан тыш;

арендаланган дәүләт мөлкәтен сатып алуга КУЭ субъектларының өстенлекле хокукы тормышка ашырылган мөлкәтне алыштыру максаты белән Исемлеккә ел саен яңа объектлар өстәү;

Исемлеккә кертелгән мөлкәткә ихтыяҗ: КУЭ субъектларына озак сроклы арендага бирелә алмый яисә алар тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла алмый торган мөлкәт Исемлегенә кертелмәү.

2019 елда ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан казна

милкенә карата 13 аукцион оештырылды, шул исәптән 10 аукцион – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен. Моннан тыш, «Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү» максатчан моделе күрсәткечләренә ирешү максатыннан ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнарының башкарма органнары белән консультатив һәм мәгълүмати эш дәвам итә. Нәтиҗәдә, Татарстан Республикасы муниципаль районнарында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлекләрендә мөлкәт составын киңәйтү буенча уңай динамика күзәтелә.

### Гомуми практика табиблары офислары өчен биналар сатып алу

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 15 ноябрь, 2303-б номерлы боерыгы  нигезендә 2014 елда Татарстан Республикасы халкына беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүне камилләштерүгә юнәлтелгән чараларны тормышка ашыру максатыннан ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан гомуми практика табиблары офислары өчен яңа төзелмәләрнең беренче катларында биналар сатып алуның дәүләт заказчысы итеп билгеләнде.

### Дәүләт милке белән идарә иткәндә бәяләү эшчәнлеге

Дәүләт активлары белән идарә итүдәге бәяләү эшчәнлеге мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора. ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы йөзендә Татарстан Республикасы бәяләү хезмәтләрен эре кулланучы булып кала бирә, чөнки дәүләт мөлкәте объектларының бәясен бәяләү аларны әйләнешкә керткәндә мәҗбүри булып тора, базар бәяләве нәтиҗәләре нигезендә дәүләт милкенә карата идарә карарлары кабул ителә.

### Дәүләт милкен бәяләү турындагы хисапларга экспертиза

Кабул ителгән чараларга карамастан, бәяләү турындагы хисаплар закон нормаларына һәрвакыт туры килми, бәяләүчеләр еш кына хисаплардагы тупас хаталарга юл куя, бу күпчелек очракта бәяләү объектының йомгаклау бәясенә сизелерлек йогынты ясый.

2019 елда ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгечләре тарафыннан дәүләт мөлкәтен, дәүләт унитар предприятиеләре һәм устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше булган акционерлык җәмгыятьләре мөлкәтен бәяләү турындагы 915тән артык исәп-хисапка экспертиза ясалды:

бүлмәләр, җиһазлар өчен аренда түләве – 840 объект;

күчемсез милек объектлары – 153 берәмлек;

корылмалар, җиһазлар – 9 678 объект;

автотранспорт – 396 берәмлек;

акцияләр пакетлары – 34 берәмлек;

җир кишәрлекләре – 76 берәмлек.

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгечләре тарафыннан

башкарыла торган экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләү турындагы хисапларның 25 – 30 проценты бәяләү эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килмәү сәбәпле, эшләп бетерү өчен кире кайтарыла, бу тапшырыла торган хисапларның түбән сыйфаты турында сөйли. Шул ук вакытта түбәндәге төп бозулар билгеләнде:

исәпләүләрдә методологик һәм арифметик характердагы хаталар;

хисаплар төзүгә мәҗбүри таләпләрне бозу (кулланыла торган мәгълүмат чыганакларына, фотофиксация материалларына сылтамалар булмау);

йомгаклау базар бәясен бозуга китерә торган төзәтмәләр кертү;

аренда түләве бәясен һәм объектларны сату базар бәясен киметү;

алар биләгән җир кишәрлекләрен исәпкә алмыйча күчемсез милек объектларын бәяләү;

аларда урнашкан күчемсез милек объектларының бәясен исәпкә алмыйча җир кишәрлекләрен бәяләү;

бәяләү турында хисапларны тулы булмаган күләмдә, кушымталардан башка бирү;

бәяләүнең актуаль булмаган датасы.

Кабатланган хаталар белән хисаплар «Татарстан Республикасының бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган партнерлыгының Эксперт советына бәйсез экспертиза үткәрү өчен җибәрелә.

Бәяләү турындагы исәп-хисапларны экспертлар карап тикшергәннән һәм бәяләү эшчәнлеге турындагы гамәлдәге законнарга туры килү-килмәү турындагы нәтиҗә белән коллегиаль һөнәри фикер кабул ителгәннән соң экспертларның бәяләүчеләр белән алга таба хезмәттәшлеге схемасы төзелде, ул бәяләү сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән, аерым алганда: бәяләүче тарафыннан сыйфатсыз эшләрне берничә тапкыр башкарганда һәм экспертларның рекомендацияләрен үтәмәгәндә бәяләүчеләрнең үзкөйләнешле оешмасына һәм Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсенә, әлеге оешмага карата дисциплинар җәза чаралары күрү өчен бәяләү оешмасына дәлилләнгән шикаять җибәрү турында карар кабул ителде.

Сәнәгать җитештерүе өчен җир бирү буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы сәнәгать җитештерүе өчен җир бирү буенча, шул исәптән нефть чыгару объектлары өчен дә, дәүләт сәясәтен тормышка ашырып, җир кишәрлекләре категориясен үзгәртү буенча актив эш алып бара. Нефть чыгару тармагын үстерү өчен бу эш аеруча зур әһәмияткә ия.

2017 – 2019 еллар өчен җир кишәрлекләрен бер категориядән төзелеш өчен яраклы икенче категориягә күчерү турында мәгълүмат

| Күчерү төре | 2017 ел | | | 2018 ел | | | 2019 ел | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | саны, берәмлек | | мәйданы, га | саны, берәмлек | | мәйданы, га | саны, берәмлек | | мәйданы, га |
| | җир кишәрлекләре | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары | | җир кишәрлекләре | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары | | җир кишәрлекләре | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Нефть чыгару объектлары өчен | 281 | 104 | 655,3 | 415 | 130 | 824,2 | 518 | 76 | 802,98 |
| Карьерларны эшкәртү өчен | 22 | 10 | 78 | 7 | 3 | 29,3 | 9 | 3 | 50,24 |
| Элемтә объектлары связи өчен (шул исәптән кәрәзле элемтәнең база станцияләре) | 37 | 13 | 1,1 | 3 | 2 | 0,1 | 0 | 0 | 0 |
| Автомобиль юллары төзелеше өчен | 7 | 3 | 14,3 | 3 | 1 | 7,6 | 1 | 1 | 12,9 |
| АЯСС һәм юл сервисының башка объектлары төзелеше өчен | 19 | 11 | 24,7 | 21 | 9 | 75,1 | 3 | 3 | 5,2 |
| Сәнәгатьнең башка объектлары өчен | 72 | 23 | 841,3 | 191 | 76 | 184,1 | 320 | 63 | 725,33 |
| Аеруча саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләренә | 0 | 0 | 0 | 7 | 5 | 9,8 | 4 | 1 | 5,99 |
| Барысы | 438 | 164 | 1 614,7 | 647 | 226 | 1 130,2 | 855 | 147 | 1 602,64 |

## Татарстан Республикасы милкенең җир кишәрлекләренә хокукын дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итү. Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләре белән эш итү

2019 елда Татарстан Республикасы милкенә хокукларны дәүләт теркәве үткәрелде һәм Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына 212,32 гектар мәйданлы 136 җир кишәрлеге кертелде.

2019 елда ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы милкенәндәге гомуми мәйданы 652,75 гектардан артык булган 163 җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга һәм түләүсез файдалануга тапшырылды.

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан гомуми мәйданы 45,46 гектардан артык булган 29 җир кишәрлеге муниципаль милеккә тапшырылды.

Кадастр мөнәсәбәтләре өлкәсендә эшчәнлек

Дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү.

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы боерыклары белән дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләре расланды:

Казан шәһәре торак пункты җирләре составындагы җир кишәрлекләре (2013 ел, 25 ноябрь, 927-б номерлы боерык);

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак һәм торак булмаган күчемсез милек объектлары (җир кишәрлекләреннән тыш) (2014 ел, 24 ноябрь, 2572-б номеры боерык);

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан сәнәгать һәм башка махсус билгеләнештәге (торак пунктлардан тыш) җирләр составындагы җир кишәрлекләре (2014 ел, 24 ноябрь, 2573-б номерлы боерык);

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак пункт җирләре составындагы җир кишәрлекләре (Казан шәһәре торак пункты җирләреннән тыш) (2015 ел, 25 ноябрь, 2846-б номерлы боерык);

Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр (2018 ел, 30 октябрь, 3647-б номерлы боерык);

Татарстан Республикасы территориясендәге су фонды, урман фонды, аеруча саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләре (2009 ел, 01 октябрь, 3087-б номерлы боерык).

Хәзерге вакытта ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының сәнәгать һәм башка махсус билгеләнештәге җирләренә дәүләт кадастр бәяләве үткәрү турындагы» 2009 ел, 15 июль, 2202-б номерлы боерыгы нигезендә «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе Татарстан Республикасының сәнәгать һәм башка махсус билгеләнештәге җирләренә кадастр бәяләве үткәрүгә кереште.

Салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлеген раслау.

Бинаның фактик кулланылышын билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү тәртибен һәм Салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карап тикшерү буенча комиссия турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче карарын үтәү йөзеннән ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карау буенча комиссия төзү турында» 2017 ел, 29 сентябрь, 2196-б номерлы боерыгы белән төзелгән салым салу максатларында биналарны

(төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карау буенча комиссия эшли.

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2019 ел, 25 ноябрь, 3711-б номерлы боерыгы нигезендә, 2020 елга салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлеге расланды. 2020 елга тиешле исемлеккә 447 күчемсез милек объекты кертелгән.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә күчемсез милекне инвентаризацияләү үткәрү.

Хәзерге вакытта Россия Федерациясенең барлык субъектларында бюджетның керем өлешен тулыландыруга аерым игътибар бирелә. Җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына салымнар җирле үзидарә органнары бюджетларының нигезе булып тора. Шуңа бәйле рәвештә, һәр объект Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән хокукларга ия булырга тиеш.

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан күчемсез милек объектларын инвентаризацияләү алгоритмы эшләнде, һәр муниципаль район һәм җирлек буенча тиешле объектларның исемлеге әзерләнде һәм эшләрне башкару өчен муниципаль берәмлекләргә җибәрелде.

Күчемсез милек объектларының кадастр бәясен дәгъвалау.

Кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен дәгъвалауның гамәлдәге тәртибе кызыксынган затларның Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе каршындагы кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләре турындагы бәхәсләрне карау комиссиясенә (2019 ел, 14 ноябрь, б/0476 нче боерыгы белән расланган) яисә судка мөрәҗәгать итү мөмкинлеген күздә тота.

2019 ел нәтиҗәләре буенча күрсәтелгән комиссия физик һәм юридик затларның 345 гаризасын карауга кабул итте.

Карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кадастр бәясен яңадан карау турындагы күпчелек гаризалар мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан закон таләпләренә туры килми торган күчемсез милек объектларының базар бәясен билгеләү турында хисап бирү һәм күчемсез милек объектларының кадастр бәясен үткәргәндә дөрес булмаган мәгълүматлардан файдалану фактлары расланмау сәбәпле кире кагылды.

2017-2019 елларда кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләре турында бәхәсләрне карау буенча комиссия тарафыннан каралган кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен яңадан карау буенча гаризалар саны динамикасы

| Ел | 2017 | 2018 | 2019 |
|---|---|---|---|
| Гаризалар күләме, берәмлек | 340 | 354 | 345 |

2019 елга кадәр кадастр бәясен яңадан карау нәтиҗәләре салым салу максатларында тиешле гариза бирелгән елның 1 гыйнварыннан файдаланылды. Димәк, кадастр бәясеннән чыгып исәпләнгән салымны яңадан исәпләү, үзгәргән очракта, ул бары тик календарь ел эчендә генә тормышка ашырылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Югары суды тарафыннан каралган күчемсез милек объектларының кадастр бәясен яңадан карау буенча административ эшләрне анализлау күрсәткәнчә, мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан күчемсез милек объектларын бәяләү турында закон таләпләренә туры килми торган исәп-хисапларның базар бәясен дәлилләү сыйфатында тапшыру практикасы саклана. Шуның нәтиҗәсендә эш буенча суд экспертизасы үткәрү зарурлыгы туа. 2019 елда үткәрелгән суд экспертизалары нәтиҗәләре буенча, анализланган 355 хисапның 323е экспертлар тарафыннан бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми дип танылды.

Югарыда күрсәтелгән суд экспертизаларын үткәрү күчемсез милек объектларының кадастр бәясен дәгъвалаудан елына 78,0 млн. сумга салым югалтуларын булдырмый калырга мөмкинлек бирде. Россия Федерациясе Салым кодексына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2019 елның 1 гыйнварыннан күчемсез милек объектларының кадастр бәясен яңадан исәпләгәндә, мөрәҗәгать иткән елга кадәрге өч ел эчендә салым югалтуларын булдырмау өчен 234,0 млн. сумнан артык акча каралган.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт милке составын һәм структурасын оптимальләштерү

2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне федераль милеккә тапшыру турында мәгълүмат

| Ел | Күчмә милек | Күчемсез милек |
|---|---|---|
| 2017 | "Полиция турында" 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру кысаларында гомуми бәясе 122,0 млн. сумнан артык булган 68 автотранспорт чарасы һәм башка күчемсез мөлкәт чарасы | 31 күчемсез милек объекты, шул исәптән 29 551,2 кв. метр мәйданлы 25 бина (бүлмә);<br>2,9 гектар мәйданлы 6 җир кишәрлеге |
| 2018 | Гомуми бәясе 113,0 млрд. сумнан артык булган 212 автотранспорт чарасы һәм башка күчемсез мөлкәт | гомуми мәйданы 3 176,9 кв. метр булган 6 күчемсез милек объекты |
| 2019 | 84,1 млн. сумлык 108 автотранспорт чарасы һәм гомуми бәясе 208,6 млн. сум булган башка күчемсез милек | гомуми бәясе 14,54 млн. сум булган, гомуми мәйданы 1 926,6 кв. метр булган 5 күчемсез милек объекты |

Россия Федерациясе Оборона министрлыгы һәм Татарстан Республикасы арасында 2013 елның 1 февраленнән күчемле һәм күчемсез милек объектларын тапшыру буенча үзара багланышлар һәм хезмәттәшлек турындагы килешү нигезендә, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 207 номерлы, 2014 елның 4 июлендәге 512 номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 24 декабрь, 2740-б номерлы

боерыгы нигезендә ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Казан шәһәренең Академик Глушко ур., 6 адресы буенча урнашкан 4 фатирны федераль милеккә тапшыру буенча чаралар үткәрелде (ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2019 ел, 07 март, 606-б боерыгы), Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Идел буе-Урал җирле мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе балансында беркетеп.

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне 2006 – 2019 елларда муниципаль милеккә тапшыру турында мәгълүмат

| Мөлкәт төренең исеме | Саны, берәмлек |
|---|---|
| Дәүләт учреждениесе | 5 124 |
| Дәүләт унитар предприятиесе | 29 |
| Дәүләт учреждениеләренә һәм предприятиеләргә беркетелгән күчемсез милек объектлары | 98 951 |
| Торак күчемсез милек объектлары | 38 466 |
| Акционерлык җәмгыятьләренең акцияләр пакетлары | 77 |


«Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан төзелгән объектларны муниципаль милеккә тапшыру турында мәгълүмат

| Объект исеме | Саны, берәмлек | Бәясе, мең сум |
|---|---|---|
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары | 23 | 1 008 873,03 |
| Мәгариф оешмалары | 18 | 2 409 802,28 |
| Фельдшер-акушерлык пунктлары | 46 | 114 087,52 |
| Табиб амбулаторияләре | 10 | 97 804,69 |
| Күпфункцияле үзәкләр | 24 | 180 229,3 |
| Универсаль спорт мәйданчыклары | 113 | 412 506,52 |
| Башкарма комитетларның (җирлек Советларының) административ биналары) | 5 | 236 186,91 |
| Блок-модульле чаңгы базалары | 13 | 82 436,26 |
| Иҗтимагый киңлекләр | 38 | 1 403 674,59 |
| Барысы | 290 | 5 945 601,1 |

Дәүләт унитар предприятиеләре санын киметү

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы эшләмәгән предприятиеләрне ачыклау һәм Юридик затларының бердәм дәүләт реестрыннан чыгару буенча актив эшен дәвам итә. Шулай итеп, соңгы 10 ел эчендә Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре саны 18 тапкырга да кимегән.

2010 – 2019 елларда Татарстан Республикасында унитар предприятиеләр саны динамикасы, берәмлек




Татарстан Республикасы милкендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган 12 унитар предприятиене калдыру планлаштырыла.»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Гамәлдәге законнар белән билгеләнгән гражданнарның мөлкәт хокукларын тәэмин итүне оештыру

Күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү һәм «ДОМ.РФ» акционерлык җәмгыяте белән хезмәттәшлек итү»

Татарстан Республикасында җир кишәрлекләре формалаштыру һәм аларны күпбалалы гаиләләргә бирү эше дәвам итә.

Ана капиталы белән беррәттән, бушлай җир участогы алу мөмкинлеге күпгаиләләр өчен мөһим стимул бирүче чара булып тора һәм, һичшиксез, гаилә институтын үстерүгә һәм туучылар санын арттыруга ярдәм итә.

2012 – 2019 елларда күпбалалы гаиләләрне җир кишәрлекләре белән тәэмин итү динамикасы

(берәмлек)

| Ел | Җир кишәрлекләре алу хокукына ия һәм ия булган күпбалалы гаиләләр саны | Җир кишәрлекләре алу хокукына ия һәм ия булган күп балалы гаиләләр саны бер ел эчендә арта | Җир кишәрлекләре белән тәэмин ителгән күп балалы гаиләләр саны | Җир кишәрлекләре белән тәэмин ителгән күп балалы гаиләләр саны |
|---|---|---|---|---|
| 2012 | 24 817 | - | 14 749 | - |
| 2013 | 29 131 | 4 314 | 19 549 | 4 800 |
| 2014 | 33 371 | 4 240 | 22 854 | 3 305 |
| 2015 | 38 514 | 5 143 | 24 160 | 1 306 |
| 2016 | 43 955 | 5 441 | 27 067 | 2 907 |
| 2017 | 49 929 | 5 974 | 28 684 | 1 617 |
| 2018 | 54 632 | 4 703 | 32 514 | 3 830 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2019 | 60 300 | 5 668 | 35 167 | 2 653 |

Җирле үзидарә органнары мәгълүматларына караганда, 2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында барлыгы 60,3 меңнән артык күпбалалы гаилә теркәлгән, шулардан 55,08 мең гаилә кишәрлек алу исемлегенә кертелгән. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү процессын оештыру буенча эш алып барыла. Нәтиҗәдә, 35,17 мең күпбалалы гаилә җир кишәрлекләре алды.

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирүнең барышы турында мәгълүмат

(берәмлек)

| Күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирүнең төп күрсәткечләре | Татарстан Республикасы буенча барлыгы | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Казан ш. | Чаллы ш. |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Күпбалалы гаиләләр саны | 60 300 | 16 333 | 7 481 |
| Исемлеккә кертү турында карар кабул ителде | 55 075 | 13 576 | 7 258 |
| Кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләре | 40 420 | 7 234 | 3 157 |
| Гомуми өлешле милеккә бирелгән җир кишәрлекләре | 35 167 | 5 532 | 2 617 |

Кайбер районнарда җир кишәрлекләре бирү эше өстәмә җир кишәрлекләре эзләү һәм ызанлау процедурасы үткәрү белән бәйле рәвештә туктатылды. Күп балалы гаиләләр өчен өстәмә җир кишәрлекләре формалаштыру буенча эшләрне финанслау мәсьәләсе дә катлаулы булып кала.

Хәзерге вакытта Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү мәсьәләсе кискен тора.

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан «ДОМ.РФ» акционерлык җәмгыяте белән Россия Федерациясе милкендә булган җир кишәрлекләренә карата хезмәттәшлек башкарыла. Бу эш ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының җир-мөлкәт өлкәсендәге эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләренең берсе булачак.

Дәүләт торак сәясәтен тормышка ашыруда катнашу

Социаль ипотека торак төзелеше программасы кысаларында 2020 елның 1 гыйнварына республика бюджетына 13 794,92 млн. сум кергән. 2019 елга план йөкләмәсе 9 248,12 млн. сумнан артык күләмдә билгеләнгән.

Моннан тыш, хисап елында җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертү буенча эш дәвам ителде. ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан 2019 елда әзерләнгән документлар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Казан шәһәре

территориясендә 163,95 гектар мәйданлы дүрт җир кишәрлеген Татарстан Республикасы дәүләт җир резервына кертү турында өч боерык кабул ителде.»;

Программаның II бүлегендә:

утыз өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гамәлдәге законнар белән билгеләнгән гражданнарның мөлкәт хокукларын тәэмин итүне оештыру» бурычы кысаларында Татарстан Республикасының күпбалалы гаиләләренә җир кишәрлекләре бирү һәм Намуссыз төзүчеләрдән зыян күргән затларга ярдәм итү республика фонды мөлкәтен гамәлгә куючы вәкаләтләре кысаларында тулыландыру буенча чараларны үтәү зарур.»;

утыз бишенче абзацта «2022» саннарын «2023» саннарына алмаштырырга;

кырык дүртенче абзацта «69» саннарын «71» саннарын алмаштырырга;

кырык алтынчы абзацта «2022» саннарын «2023» саннарына алмаштырырга;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Программаны финанслауның гомуми күләме 14 936,63 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

2014 ел – 1 016,48 млн. сум;
2015 ел – 3 376,21 млн. сум;
2016 ел – 1 886,84 млн. сум;
2017 ел – 1 415,82 млн. сум;
2018 ел – 3 734,22 млн. сум;
2019 ел – 2 331,99 млн. сум;
2020 ел – 437,46 млн. сум;
2021 ел – 242,41 млн. сум;
2022 ел – 247,6 млн. сум;
2023 ел – 247,6 млн. сум.

Программаны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган финанслау күләме ел саен Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә ачыкланачак.»;

Программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин